Татарстан Республикасы муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Советы

КАРАР № 6 КАРАР

Иске Кәшер авылы 2016 елның 01»феврале

Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Советының 2015 елның 29 гыйнварында кабул ителгән карары нигезендә, Сарман муниципаль районы № 6» референдум үткәрү инициативасы турында", Иске Кәшер авыл җирлеге Советы хәл итә:

1. Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 мартына гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Без 2016 елда Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I-III төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан , вакытлы хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

"2016 елда Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I -11 төркем инвалидларыннан, көндезге бүлек студентларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, хәрби хезмәттәге хәрби хезмәткәрләрдән тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- җирлек территориясендә физик культура, мәктәп һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;;

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп) ;

- каты коммуналь калдыкларны җыю( шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге ;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту .

«ӘЙЕ, »ЮК".

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кәшер авыл жирлеге башлыгы: Р. Н. Дәүләтҗанов